**Татарстан Республикасы**
**Арча муниципаль районынын**
**Арча шәһәр муниципаль берәмлеге**
**Арча шәһәр Советы**
**422000, Арча ш. Совет майданы, 27**

**тел. 3-16-25, 3-12-35**

**Муниципальное образование**
**город Арск**
**Арского муниципального**
**района Республики Татарстан**
**Совет города Арск**
**422000,г. Арск, площадь Советская , 27**

**тел. 3-16-25, 3-12-35**

**Арча шәһәре Советы**

**КАРАРЫ**

**« 18 » 12 2019 ел** **№ 137**

**«Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Арча шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясендә автомобиль кую урыннарын оештыру Тәртибен раслау турында» 2014 елның 26 декабрендәге 28 номерлы Арча шәһәре Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

“Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, “Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында” 1995 елның 24 декабрендәге 181-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2001 елның 17 декабрендәге 795 номерлы карары белән расланган автомобиль кую урыннары хезмәтләре күрсәтү Кагыйдәләре нигезендә, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы “Арча шәһәре” муниципаль берәмлеге территориясендә транспорт чараларын саклау урыннарын (кую) оештыруны тәртипкә салу максатларында Арча шәһәре Советы КАРАР БИРДЕ:

1. «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының «Арча шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясендә автомобиль кую урыннарын оештыру Тәртибен раслау турында» Арча шәһәре Советының 2014 елның 26 декабрендәге 28 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Арча шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясендә автомобиль кую урыннарын оештыру Тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2.10 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.10.Транспорт чараларын кую урынының (тукталыш) һәрберсендә, шул исәптән социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктурасы объектлары (торак, иҗтимагый һәм җитештерү биналары, төзелешләр һәм корылмалары, физик культура-спорт оешмалары, мәдәният оешмалары һәм башка оешмалар урнашкан), ял итү урыннары янында I, II төркем инвалидлар, шулай ук III төркем инвалидлар тарафыннан идарә ителә торган транспорт чараларын һәм мондый инвалидларны һәм инвалид балаларны утыртып йөртүче транспорт чараларын кую өчен Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә кимендә 10 процент (бер урыннан да ким булмаган) бушлай кую урыны бүлеп бирелә. Әлеге транспорт чараларында "Инвалид"дигән тану билгесе булырга тиеш. "Инвалид" тану билгесен шәхси файдалану өчен бирү тәртибе Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан бирелгән вәкаләтле башкарма хакимият федераль органы тарафыннан билгеләнә. Әлеге урыннарны башка транспорт чаралары биләргә тиеш түгел.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында (http:arsk.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге Карарның үтәлешен тикшереп торуны Арча шәһәре башкарма комитеты җитәкчесенә йөкләргә.

"Арча шәһәре" муниципаль берәмлеге башлыгы,
Арча шәһәр Советы рәисе И.Г. Нуриев